ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/8

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне кушымтада каралган тәртиптә расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының ««Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәне раслау хакында» 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 6 гыйнвардагы 1 нче, 2012 ел, 11 гыйнвардагы 2 нче саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 39/15 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 ел, 13 майдагы 34 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 24 апрельдәге 30 нчы санында басылган;

3) Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге «Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы

муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 7/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2016 ел, 13 апрельдәге 26 нчы санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2016 ел, 20 апрельдәге 28 нче санында басылган;

4) Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге «Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 17/6 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 28 июнендәге 46 нчы санында басылган;

5) Шәһәр Советының 2019 елның 23 маендагы «Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/12 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 31/9 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2019 ел, 5 июньдәге 39 нчы санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 ел, 7 июньдәге 40 нчы санында басылган.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г.Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
9/8 Карарына
кушымта
3 ноябрь, 2021 ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә

1 статья. Контроль-хисап палатасы статусы

1. «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Контроль-хисап палатасы) – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ШәҺәр Советы (алга таба – Шәһәр Советы) тарафыннан төзелгән һәм аңа хисап бирә торган тышкы муниципаль финанс контролендә даими эшләүче орган.
2. Контроль-хисап палатасы оештыру һәм функциональ бәйсезлеккә ия һәм үз эшчәнлеген мөстәкыйль гамәлгә ашыра.
3. Контроль-хисап палатасының эшчәнлеге туктатыла алмый, шул исәптән Шәһәр Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта да.
4. Контроль-хисап палатасы юридик зат хокукларына ия, исеме язылган һәм Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре гербының рәсеме төшерелгән герблы мөһере һәм бланклары бар.
5. Контроль-хисап палатасы бүләкләр һәм аерымлык билгеләре булдырырга, әлеге бүләкләр һәм билгеләр турында нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен расларга мөмкин.
6. Контроль-хисап палатасы урнашкан җирлек – Яр Чаллы шәһәре.

2 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенең хокукый нигезләре

Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Нигезләмә һәм башка муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә башкара.

3 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге принциплары

Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

4 статья. Контроль-хисап палатасы составы

1. Контроль-хисап палатасы рәис, рәис урынбасары, аудиторлар һәм контроль-хисап палатасы һәм Контроль-хисап палатасы аппараты составында

төзелә.

2. Рәис, рәис урынбасары һәм аудитор вазыйфалары муниципаль вазыйфалар булып санала.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторларының вәкаләтләре вакыты  алты елны тәшкил итә.

4. Контроль-хисап палатасында Контроль-хисап палатасы Коллегиясе оештырыла, аның составына Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлар керә.

5. Контроль-хисап палатасы аппараты составына инспекторлар һәм башка штат хезмәткәрләре керә. Контроль-хисап палатасы инспекторларына тышкы муниципаль финанс контролен оештыру һәм үткәрү бурычы йөкләнә.

6. Контроль-хисап палатасы хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Контроль-хисап палатасы Регламенты, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

7. Контроль-хисап палатасының штат саны 6 кешедән тора.

8.Контроль-хисап палатасының структурасы һәм штат расписаниесе Контроль-хисап палатасына йөкләнгән вәкаләтләрдән чыгып, Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан раслана.

## 5 статья. Контроль-хисап палатасы рәисен, рәис урынбасарын һәм аудиторларын  вазыйфага билгеләү тәртибе.

1. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлар вазыйфага Шәһәр Советы тарафыннан ачык тавыш бирү тәртибендә Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән билгеләнә.

2. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр Шәһәр Советына кертелә:

1) Шәһәр Хакиме тарафыннан;

2) Шәһәр Советы депутатлары – Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән санының кимендә өчтән бере –  тарафыннан.

3. Шәһәр Советы Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатураларның «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүе турында бәяләмә алу өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларына кандидатуралар Шәһәр Советына Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан кертелә.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау тәртибе Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/6 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты белән билгеләнә.

## 6 статья. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларын биләүгә кандидатураларга таләпләр

1. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлар вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белемле булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эшләү тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджетта хокукны җайга салучы башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекнең контроль һәм эксперт-аналитик чараларын уздыру өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына гомуми таләпләрне таләпләрне белү.

2. Түбәндәге очракларда Россия Федерациясе гражданины Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнми:

1) суд хөкеме алынмаганда яисә суд хөкемен үтәп бетермәгәндә;

2) закон көченә кергән суд карары белән хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикләнгән дип танылганда;

3) дәүләт серен тәшкил иткән һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматка рөхсәт рәсмиләштерү процедурасын узудан баш тартканда, әгәр гражданин дәгъва кыла торган вазыйфаны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булса;

4) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктау, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;

5) әлеге статьяның 3 өлешендә каралган нигезләр булу.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары шәһәр Хакиме, Башкарма комитеты җитәкчесе, шәһәр территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта яисә ире (хатыны) ягыннан туганлыкта (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук иренең (хатынының) абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары балалары) була алмый.

4. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшк белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек тулысынча чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшырырга тиеш.

Күрсәтелгән вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы затлар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш.

6. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә һәм вазыйфаларны башкарырга тиеш.

### 7 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары статусы гарантияләре

1. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары, инспекторлары Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары булып санала.

2.Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына аларның вәкаләтләрен башкаруга комачаулык итү яисә алар тарафыннан карар кабул итүгә йогынты ясау максатында нинди дә булса формада тәэсир иткән өчен, шулай ук Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына карата көч кулланган, кимсеткән, яла яккан яисә аларның эшчәнлекләре хакында күрәләтә ялган мәгълүмат биргән өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка тарту каралган.

3. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары судьяларны, хокук саклау һәм контроль органнарының вазыйфаи затларын дәүләт яклавы турындагы Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт тарафыннан якланырга тиеш.

4. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары һөнәри бәйсезлек гарантияләренә ия.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары, түбәндәге очракларда, Шәһәр Советы карары нигезендә, вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителә:

1) аларга карата гаепләү хөкеме законлы көченә кергәндә;

2) закон көченә кергән суд карары белән хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикләнгән дип танылганда;

3) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктатканда, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;

4) отставкага китү турында язмача гариза биргәндә;

5) вәкаләтләрен башкарганда Россия законнары таләпләрен бозган яисә вазыйфаи вәкаләтләреннән законсыз файдаланган очракта, әгәр вакытыннан алда карар кабул итү өчен Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге тавыш бирсә;

6) вазыйфаны биләүнең законда билгеләнгән иң чик яшенә җиткәндә;

7) әлеге Нигезләмәнең 6 статьясындагы 2-3 өлешләрендә каралган хәлләр ачыкланганда;

8) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетларга (кертемнәргә) ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгәндә, вазыйфаларны башкармаганда.

8 статья. Контроль-хисап палатасының төп вәкаләтләре

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге төп вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль берәмлек бюджеты средстволарын, шулай ук, Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, башка средстволарны куллануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) муниципаль берәмлек бюджеты проектларына экспертиза ясау, аның күрсәткечләренең нигезлелеген тикшерү һәм анализлау;

3) муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милекне формалаштыру, аның белән идарә итү һәм мондый милек белән эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милекне

формалаштыруның, идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә карата аерым хокукларны да кертеп) үтәүне тикшереп тору;

6) муниципаль берәмлек бюджеты средстволары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль берәмлек бюджеты һәм муниципаль милектәге мөлкәт хисабына башкарыла торган килешүләр буенча яисә үтәүнең башка ысуллары буенча йөкләмәне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) муниципаль хокукый актлар проектларына муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә экспертиза ясау, муниципаль берәмлек бюджеты керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программа проектларына) экспертиза ясау;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессына анализ ясау һәм мониторинг үткәрү, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган кимчелекләрне бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында муниципаль берәмлек бюджеты үтәлешенә һәм үтәлешне оештыруга оператив анализ ясау һәм контрольдә тоту, муниципаль берәмлек бюджетының үтәлеше барышы турында, уздырылган контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында Шәһәр Советына һәм шәһәр Хакименә квартал саен мәгълүмат тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурычны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

11) муниципаль берәмлекнең стратегик планлаштыру документларында каралган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешүнең гамәлгә ашырылуын, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен Контроль-хисап палатасы компетенциясе чикләрендә бәяләү;

12) коррупциягә каршы чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу;

13) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, шәһәр уставында, муниципаль берәмлекнең Шәһәр Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.

2. Контроль-хисап палатасы тышкы муниципаль финанс контролен:

1) җирле үзидарә органнарына, муниципаль органнарга, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль унитар предприятиеләргә, шулай ук, әгәр алар муниципаль берәмлек милкендәге мөлкәттән, устав капиталында муниципаль берәмлекнең катнашу өлеше булган оешмалардан файдалансалар, башка оешмаларга карата;

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда башка затларга карата үткәрә.

9 статья. Контроль-хисап палатасы тарафыннан тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру формалары

1. Тышкы муниципаль финанс контроле Контроль-хисап палатасы тарафыннан контроль яисә эксперт-аналитик чаралар рәвешендә гамәлгә ашырыла.

2. Контроль-хисап палатасы контроль чара үткәргәндә тиешле акт (актлар) төзелә, ул тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә. Акт (актлар) нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан хисап төзелә.

3. Эксперт-аналитик чараны үткәргәндә Контроль-хисап палатасы хисап яисә бәяләмә төзи.

## 10 статья. Тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары

1. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук тышкы муниципаль финанс контроле стандартларына таяна.

2. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган гомуми таләпләр нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан раслана.

3. Тышкы муниципаль финанс тикшерүе стандартларын әзерләгәндә дәүләт контроле, аудит һәм финанс хисабы өлкәсендә халыкара стандартлар исәпкә алына.

4. Тышкы муниципаль финанс тикшерүе стандартлары Россия Федерациясе законнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарына каршы килә алмый.

## 11 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру

1. Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген мөстәкыйль төзелгән һәм расланган планнар нигезендә башкара.

2. Контроль-хисап палатасының эш планы планлаштырылу елы алдыннан килгән елның 30 декабренә кадәр раслана.

3. Контроль-хисап палатасының эш планына шәһәр Хакименең тәкъдимнәре, Шәһәр Советының Контроль-хисап палатасына җибәрелгән йөкләмәләре мәҗбүри кертелергә тиеш.

4. Контроль-хисап палатасының эш планын үзгәртү буенча шәһәр Хакименең, Шәһәр Советының тәкъдимнәре Контроль-хисап палатасы тарафыннан, кергән көннән алып, 10 көн эчендә карала.

## 12 статья. Контроль-хисап палатасы Регламенты

1. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге юнәлешләре, эшләр алып бару, контроль һәм эксперт-аналитик чаралар әзерләү һәм үткәрү тәртибе, Контроль-хисап палатасының эчке эшчәнлегенең башка мәсьәләләре Контроль-хисап палатасы Регламенты белән билгеләнә.

2. Контроль-хисап палатасы Регламенты Контроль-хисап палатасы

Коллегиясе тарафыннан кабул ителә һәм Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан раслана.

13 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген оештыру буенча Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вәкаләтләре

1. Контроль-хисап палатасы рәисе:

1) Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

2) шәһәр Хакименә һәм Шәһәр Советына Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре турында еллык хисап тапшыра;

3) Россия Федерациясе дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән мөнәсәбәтләрдә Контроль-хисап палатасы исеменнән эш йөртә;

4) структур бүлекчәләр турында нигезләмәләрне һәм контроль-хисап палатасы хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;

5) Контроль-хисап палатасы аппараты хезмәткәрләрен эшкә алу һәм эштән азат итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

6) контроль-хисап палатасы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар (боерыклар, күрсәтмәләр) чыгара.

2. Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфа инструкциясе һәм Контроль-хисап палатасы Регламенты нигезендә вазыйфаи бурычларын, Контроль-хисап палатасы рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара. Бер үк вакытта контроль һәм эксперт-аналитика чаралары җитәкчесе булып тора, Контроль-хисап палатасы Регламентында билгеләнгән компетенциясе чикләрендә, җитәкчелек итә торган юнәлеш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итә һәм аның нәтиҗәләре өчен җавап бирә.

3. Контроль-хисап палатасы аудиторлары контроль һәм эксперт-аналитик чаралар җитәкчеләре булып тора. Контроль-хисап палатасы аудиторлары компетенция чикләрендә, контроль-хисап палатасы Регламентында һәм вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнгән кысаларда, җитәкчелек итә торган юнәлешләр эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итәләр һәм аның нәтиҗәләре өчен җавап бирәләр.

14 статья. Контроль-хисап палатасы Коллегиясе компетенциясе

Контроль-хисап палатасы Коллегиясе үз утырышларында түбәндәге мәсьәләләрне карый:

1) Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында еллык хисап;

2) Контроль-хисап палатасының эш планнары;

3) тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары;

4) контроль һәм эксперт-аналитик чаралар йомгаклары; Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрү;

5) Контроль-хисап палатасы Регламентында каралган башка мәсьәләләр.

## 15 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары таләпләрен үтәүнең мәҗбүрилеге

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфаи вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле таләпләре һәм сораулары җирле үзидарә органнары, тышкы муниципаль финанс контроле гамәлгә ашырыла торган оешмалар (алга таба – тикшерелә торган органнар һәм оешмалар) яисә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматка ия органнар тарафыннан үтәлү өчен мәҗбүри булып тора.

2. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының законлы таләпләрен һәм сорауларын (запрос) үтәмәгән, шулай ук аларга йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга комачаулаган өчен гамәлдәге законнар белән җаваплылык каралган.

3. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләре Контроль-хисап палатасының тиешле вазыйфаи затларын белешмә-хокукый системаларга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә керү мөмкинлеге булган җиһазланган эш урыны белән тәэмин итәргә бурычлы.

4. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасына вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалану рөхсәт ителә.

## 16 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары вазыйфаи вәкаләтләрен башкарганда хокуклы:

1) тикшерелә торган органнар һәм оешмалар биләгән территориягә һәм биналарга тоткарлыксыз керергә, аларның документлары һәм материаллары белән танышу мөмкинлегенә ия булырга, шулай ук алар биләгән территорияләрне һәм бүлмәләрне карарга;

2) ялганлау, төзәтү, урлау, хезмәт урыныннан явызларча файдалануны ачыкланганда һәм әлеге хокукка каршы гамәлләрне булдырмау максатында, тикшерелүче органнар һәм оешмаларның кассалар, касса һәм хезмәт бүлмәләрен, складларын һәм архивларын печатьләп куярга, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, документлар һәм материалларны алырга. Кассаларны, касса һәм хезмәт урыннарын, складларны һәм архивларны печатьләп кую, документлар һәм материалларны алу тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның вәкаләтле вазыйфаи затлары катнашында һәм тиешле актлар төзү белән башкарыла;

3) компетенциясе кысаларында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең, Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның вазыйфаи затларына сораулар (запрос) җибәрергә;

4) компетенциясе кысаларында, тикшерелүче органнар һәм оешмаларның җитәкчеләреннән һәм башка вазыйфаи затларыннан тикшерү чараларын үткәргәндә ачыкланган закон бозу фактлары буенча язмача аңлатмалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган документларның күчермәләрен бирүне таләп итәргә;

5) тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү чараларын үткәргәндә соралган документларны һәм материалларны тапшырмау яисә вакытында тапшырмау фактлары буенча актлар төзергә;

6) компетенциясе кысаларында, тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы барлык кирәкле документлар, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон белән саклана торган башка серләрне үз эченә алган документлар белән танышырга;

7) тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы һәм тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның мәгълүмат базаларында электрон формада саклана торган мәгълүмат белән, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне үз эченә алган мәгълүмат белән танышырга;

8) мәгълүматларның электрон базаларына техник документлар белән танышырга;

9) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

2. Кассалар, касса һәм хезмәт урыннары, складлар һәм архивлар печатьләп куелган, документлар һәм материаллар алынган очракта, Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары бу хакта кичекмәстән (24 сәгать эчендә) әлеге статьяның 1 өлеше 2 пунктында каралганча, Контроль-хисап палатасы рәисенә гамәлдәге законнарда һәм Контроль-хисап палатасы Регламентында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә тиеш.

Язма хәбәрне вакытында тапшыру мөмкин булмаган очракта, Контроль-хисап палатасы рәисенә мөмкин булган башка ысул белән хәбәр ителә, алга таба язма хәбәр җибәрелә.

3. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның оператив-хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынырга, шулай ук контроль чаралар үткәргәндә алынган мәгълүматны таратырга, контроль чаралар тәмамланганып, тиешле актлар һәм хисаплар төзелгәнгә кадәр нәтиҗәләрне хәбәр итәргә тиеш түгел.

4. Тикшерү-хисап палатасының вазыйфаи затлары экспертиза-аналитик чаралар үткәргәндә аларга билгеле булган дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон белән саклана торган серләрне сакларга, контроль һәм экспертиза-аналитик чараларны объектив үткәрергә, тиешле актларда, хисапларда һәм бәяләмәләрдә аларның нәтиҗәләрен дөрес итеп күрсәтергә тиеш.

5. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тотуны, акчалата чаралар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турындагы» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә вазыйфаларын башкарырга, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

6. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә торган контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләренең дөреслеге һәм объективлыгы, шулай ук дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серләрне саклау өчен җаваплы.

7. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары Шәһәр Советы, аның комиссияләре һәм эш төркемнәре утырышларында, Башкарма комитет утырышларында, шәһәр Хакиме каршындагы координация һәм киңәшмә органнары утырышларында катнашырга хокуклы.

## 17 статья. Контроль-хисап палатасына мәгълүмат бирү

1. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар Контроль-хисап палатасына контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материалларны гамәлдәге законнарда һәм Контроль-хисап палатасы Регламентында билгеләнгән срокларда тапшырырга тиеш.

2. Контроль-хисап палатасы контроль чараларын гамәлгә ашырганда, тикшерелүче органнар һәм оешмалар Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына идарә итү һәм башка хисаплылык, муниципаль берәмлек бюджетын формалаштыру һәм үтәү, муниципаль берәмлек милкен куллану, тикшерелә торган оешмалар тарафыннан кулланыла торган мәгълүмат системалары һәм аларга техник документлар, шулай ук Контроль-хисап палатасы тарафыннан аның вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле башка документлар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

3. Муниципаль берәмлектә муниципаль учреждениеләр һәм унитар предприятиеләр булдыру, үзгәртеп кору яки бетерү, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында муниципаль берәмлек өлеше һәм акцияләре санын үзгәртү, бюджет акчалары һәм муниципаль берәмлек милкенең башка объектлары белән идарә итү турында шартнамәләр төзү турында Башкарма комитетның хокукый актлары кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә Контроль-хисап палатасына җибәрелә.

4. Башкарма комитетның финанс идарәсе Контроль-хисап палатасына муниципаль берәмлекнең бюджет хисабын, расланган җыелма бюджет язмасын, касса планын һәм аларга үзгәрешләрне җибәрә.

5. Муниципаль берәмлекнең бюджет средстволарының баш администраторлары Контроль-хисап палатасына җыелма бюджет хисабын

җибәрәләр.

6. Башкарма комитет ел саен Контроль-хисап палатасына муниципаль унитар предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук муниципаль берәмлек өлеше илле проценттан да ким булмаган акционерлык җәмгыятьләре эшчәнлеген аудитор тикшерүләре нәтиҗәләре буенча аудитор оешмаларының хисапларын һәм бәяләмәләрен аларга имза куелган көннән алып утыз көн эчендә җибәрә.

7. Контроль-хисап палатасына аның соравы буенча контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материалларны тапшырмау яки вакытында тапшырмау, шулай ук мәгълүмат, документлар һәм материалларны тулы күләмдә тапшырмау яки дөрес булмаган мәгълүмат, документлар һәм материаллар бирү гамәлдәге законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

## 18 статья. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләре

1. Контроль-хисап палатасы контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына ачыкланган бюджет һәм башка җитешсезлекләрне бетерү, муниципаль берәмлеккә матди зыян китерүне булдырмау яки китерелгән зыянны каплау, хокук бозуларда гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту, шулай ук бозуларны туктату, бетерү һәм кисәтү буенча чаралар күрү өчен күрсәтмәләр бирергә хокуклы.

2. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсенә Контроль-хисап палатасы рәисе кул куя.

3. Җирле үзидарә органнары, шулай ук күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта яки, әгәр срок күрсәтелмәгән булса, күрсәтмә бирелгән көннән соң 30 көн эчендә бирелгән күрсәтмәне үтәү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында Контроль-хисап палатасына язмача хәбәр итәргә тиеш. Күрсәтмәне үтәү вакыты Контроль-хисап палатасы карары буенча бер тапкыр озайтылырга мөмкин.

4. Кисәтү һәм булдырмау буенча кичекмәстән чаралар таләп итә торган закон бозулар ачыкланганда, Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләренең үтәлмәгән, шулай ук Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының контроль чаралар үткәрүенә комачаулаган очракта, Контроль-хисап палатасы Шәһәр Советына, Башкарма комитетка, тикшерелә торган оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына күрсәтмә җибәрә.

5. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсендә конкрет хокук бозулар һәм күрсәтмә чыгаруның конкрет нигезләре бәян ителергә тиеш.

6. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсенә Контроль-хисап палатасы рәисе кул куя.

7. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсе билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш. Күрсәтмәнең үтәлү вакыты Контроль-хисап палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.

8. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсен үтәмәү гамәлдәге законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

9. Муниципаль берәмлек бюджеты средстволарыыннан җинаятьчелек яки коррупцион хокук бозу билгеләре белән бәйле законсыз файдалану фактлары ачыкланган очракта, Контроль-хисап палатасы тикшерү материалларын билгеләнгән тәртиптә хокук саклау органнарына тапшыра.

## 19 статья. Тикшерелә торган органнар һәм оешмаларның хокукый гарантияләре

1. Контроль чаралар уздырганда Контроль-хисап палатасы тарафыннан төзелгән актлар тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокта тапшырылган аңлатмалары һәм искәрмәләре актларга теркәлә һәм алга таба аларның аерылгысыз өлеше булып тора.

2. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары Контроль-хисап палатасының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белән Шәһәр Советына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## 20 статья. Контроль-хисап палатасының дәүләт һәм муниципаль органнар белән хезмәттәшлеге

1. Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген тормышка ашырганда башка муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, Россия Федерациясе Үзәк Банкының территориаль идарәләре, Федераль казначылыкның территориаль органнары, салым органнары, прокуратура органнары, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка хокук саклау, күзәтчелек һәм контроль органнары белән хезмәттәшлек итәргә, алар белән хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзергә хокуклы.

2. Контроль-хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә контроль һәм эксперт-аналитика чараларын үткәрүдә катнашуга контроль, хокук саклау һәм башка органнарны һәм аларның вәкилләрен җәлеп итәргә, шулай ук, килешү нигезендә, аудитор, фәнни-тикшеренү, эксперт һәм башка оешмаларны, аерым белгечләрне, экспертларны, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.

3. Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Контроль-хисап органнары берләшмәләренә (ассоциациясенә) керергә хокуклы.

4. Үз эшчәнлеген координацияләү максатларында Контроль-хисап палатасы һәм муниципаль органнар вакытлы, даими эшләүче уртак координацион, консультацион, киңәшмә һәм башка эш органнары оештыра ала.

5. Контроль-хисап палатасы башка муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының язмача мөрәҗәгате буенча алар үткәргән контроль һәм эксперт-аналитика чараларында катнаша ала.

6. Контроль-хисап палатасы яисә Шәһәр Советы Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенең тышкы муниципаль финанс контроле турындагы законнарга һәм

аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча рекомендацияләргә туры килүе турында бәяләмә сорап Россия Федерациясе Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

21 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү

1. Контроль-хисап палатасы, үз эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү максатларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Интернет челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Контроль-хисап палатасы битендә урнаштыра һәм массакүләм мәгълүмат чараларында үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитика чаралары, аларны уздырганда ачыкланган хокук бозулар, бирелгән күрсәтмәләр, шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында мәгълүмат урнаштыра.

2. Контроль-хисап палатасы ел саен үз эшчәнлеге турында Шәһәр Советына хисап бирә. Күрсәтелгән хисап Шәһәр Советы тарафыннан карап тикшерелгәннән соң гына массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга яисә Интернет челтәрендә урнаштырыла.

3. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә мәгълүмат урнаштыру тәртибе Контроль-хисап палатасы Ррегламенты нигезендә башкарыла.

22 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген финанслау

1. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген финанслау аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган күләмдә карала.

2. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары муниципаль берәмлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

3. Контроль-хисап палатасы тарафыннан бюджет средстволарын һәм муниципаль милекне куллануны тикшерү Шәһәр Советының хокукый актлары нигезендә башкарыла.

23 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларын матди һәм социаль тәэмин итү

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү (бүләкләү), ел саен түләүле ял (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәте һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэминат чаралары гарантияләнә.

2. Контроль-хисап палатасы рәисен, рәис урынбасарын, аудиторларны, инспекторларны һәм Контроль-хисап палатасы аппаратының башка хезмәткәрләрен матди һәм социаль тәэмин итү чаралары федераль законнар,

Татарстан Республикасы законнары һәм  Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.